Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Сөләй авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

17 апрель 2023 ел — № 3

Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сөләй авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 02 августындагы 11 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 12 маендагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, 2022 елның 1 мартыннан кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 10 апрелендәге 02-08-01/179 номерлы протестын карап

Сөләй авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сөләй авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 02 августындагы 11 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Совет урамы, 53а йорты; Урсалабаш авылы, Әхмәдуллин урамы, 114а йорты; Яңа Михайловка авылы, Заречная урамы, 29а торак пункт территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сөләй авыл башкарма
комитеты җитәкчесе — А.З.Бикбаев